**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Сарлы авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Сарлы авылы №68-36 «13» ноябрь 2017 ел

2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлеге бюджеты турында (беренче укылышта)

Сарлы авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1 Статья

1. 2018 елга Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга.:

1) Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләме 2 092,5 мең сум күләмендә;

2) Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2 092,5 мең сум күләмендә;

3) Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 0,0 мең сум күләмендә.

2. 2019 елга һәм 2020 елга Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга.:

1) Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләме 2019 елга 2 131,4 мең сум һәм 2020 елга 2 173,9 мең сум күләмендә;

2) Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2019 елга 2 131,4 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 51,2 мең сум һәм 2020 елга 2 173,9 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 104,4 мең сум.

3) Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 2019 елга 0,0 мең сум һәм 2020 елга 0,0 мең сум күләмендә.

3. 2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына Сарлы авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2 Статья

1. 2019 елның 1 гыйнварына Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге муниципаль эчке бурычының югары чиге 0,0 мең сум, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча бурычның югары чиге 0,0 мең сум күләмендә расларга.

2. 2020 елның 1 гыйнварына Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге муниципаль эчке бурычының югары чиге 0,0 мең сум, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча бурычның югары чиге 0,0 мең сум күләмендә расларга.

3. 2021 елның 1 гыйнварына Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге муниципаль эчке бурычының югары чиге 0,0 мең сум, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча бурычның югары чиге 0,0 мең сум күләмендә расларга.
4. Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге муниципаль бурычының иң чик күләмен билгеләргә
2018 елда 0,0 мең сум күләмендә;
2019 елда 0,0 мең сум күләмендә;
2020 елда 0,0 мең сум күләмендә.

3 Статья
Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге бюджетында 2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына Сарлы авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәрен әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

4 Статья
1. Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.
2. Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының Баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә расларга.

5 Статья
1. Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының 2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына ведомство структурасын әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә расларга.
2. Бюджет ассигнованиеләрен 2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге бюджеты чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә расларга.
3. Бюджет ассигнованиеләрен 2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге бюджеты чыгымнары классификациясенең максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгым төрләре төркемнәре, бүлекләре, бүлекчәләре буенча бүлүне әлеге карарга 7 нче кушымта нигезендә расларга.
4. 2018 елга гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 0,0 мең сум, 2019 елга 0,0 мең сум, 2020 елга 0,0 мең сум күләмендә расларга.

6 Статья
Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлеге бюджетында 2018 елга бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Азнакай муниципаль районы бюджетыннан алына торган дотацияләр күләмен исәпкә алырга: 357,6 мең сум , 2019 елга 390,6 мең сум, 2020 елга 424,0 мең сум.

7 Статья
Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлеге бюджетында хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Азнакай муниципаль районы бюджетыннан алына торган субвенцияләр күләмен 2018 елга 82,9 мең сум, 2019 елга 83,8 мең сум, 2020 елга 86,9 мең сум итеп исәпкә алырга.

8 Статья
Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлеге җирле үзидарә органнары 2018 елда һәм 2019 һәм 2020 елларның план чорында муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

9 Статья
Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләр нигезендә Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне башкара.

10 Статья
Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге бюджетының 2018 елның 01 гыйнварына Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге исеменнән төзелгән товарлар ташуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә шушы муниципаль контрактлар шартлары нигезендә түләнергә тиешле муниципаль контрактларга түләүгә файдаланылмый калган бюджет ассигнованиеләре суммасыннан артмаган күләмдә калган акчалары 2017 елда, 2018 елда, Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлеге башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта, күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

11 Статья
Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

12 Статья
Әлеге карар 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә .

13 Статья
Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай муниципаль районы авыл җирлеге Сарлы Советының Бюджет, салымнар, финанс һәм икътисад мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис М. Р. Шәрипов